| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЭБАЛАКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯБАЛАК АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**2019 елның 21нче мае** **Ябалак авылы** **№ 7**

**Ябалак авыл җирлегенең муниципаль милкендә булган барлык биналар,ялланган йорт белән идарә итү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясе Торак кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы 2017 елның 31 декабрендәге 485-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ябалак авыл җирлеге башкарма комитеты

**КАРАР КЫЛА:**

1.Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ябалак авыл җирлеге Башкарма комитетының 2015 елның 6 мартындагы 5 номерлы «Ябалак авыл җирлеге муниципаль милкендә булган барлык биналар,ялланган йорт белән идарә итү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы карары белән расланган,Ябалак авыл җирлегемуниципаль милкендә булган барлык биналар,ялланган йорт белән идарә итү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 бүлекнең 3.7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Идарәче оешма күпфатирлы йорт белән идарә итү шартнамәсе туктатылган көннән өч эш көне эчендә күпфатирлы йортка техник документацияне һәм мондый йорт белән идарә итү белән бәйле башка документларны, күпфатирлы йорттагы биналарның милекчеләренең гомуми милке составына керә торган биналарның ачкычларын, күпфатирлы йорттагы биналарның милекчеләренең гомуми милке составына керә торган җиһазларга керүнең электрон кодларын һәм күпфатирлы йортны эксплуатацияләү һәм аларга идарә итү өчен кирәкле техник чараларны һәм җиһазларны яңа сайланган идарәче оешмага, торак милекчеләре ширкәтенә яки торак яки торак-төзелеш кооперативына, йә башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативына, ә мондый йорт хуҗалары белән турыдан-туры идарә иткән очракта, мондый йорт белән идарә итү ысулын сайлап алу турында милекчеләрнең гомуми җыелышы карарында күрсәтелгән затларга яки әлегемилекче күрсәтелмәгән очракта,мондый йорттагы теләсә кайсы милекчегә тапшырырга тиеш».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга, http://pravo.tatarstan.ru/ Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ябалак авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Татарстан Республикасы**
**Кайбыч муниципаль районы**
**Ябалак авыл җирлеге башлыгы** **Гыйзәтуллина М. Ф.**